ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧЕРНЫШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район,
д. Чернышевка , ул. Клубная, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧЕРНЫШЕВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Чернышевка авылы, Клуб ур., 1

тел./факс 8(84365) 73-5-05, e-mail:Chern.Vsg@tatar.


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29 марта 2021 г.** **№ 108**

**Чернышевка авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 65 номерлы карары белән расланган Агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын актуальләштерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карарына таянып, 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының мәсьәләләре буенча, 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсен үтәүгә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Внести в административный регламент предоставления муниципальной услуги по выдаче разрешения на вырубку, кронирование или посадку деревьев и кустарников, утвержденный постановлением исполнительного комитета Чернышевского сельского поселения от 20.02.2021 № 65, следующие изменения:

1) 2.6. бүлекнең 2.6.1. пунктындагы 2) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, бурычы булмау (булу) турында белешмә.»;

2) 2.8. бүлекнең 2.8.2. пунктын түбәндәге эчтәлекле 4) пунктча белән тулыландырырга:

«4) Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы.»;

3) 3.4. бүлекнең 3.4.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 абзац белән тулыландырырга:

«мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, бурычы булмау (булу) турында белешмәләр.»;

4) Административ регламентның 1 нче кушымтасында соңгы абзацны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Сканерланган документларның төп нөсхәләрен сораткanда бирергә йөкләмә алам. 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системага салуга, туплауга, таратуга (шул исәптән тапшыруга) һ.б.) ризалыгымны бирәм».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Чернышевка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе О.А.Маланин